БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» 07 2021 ел № 203

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы бюджетыннан беренче чиратта кирәкле товарларны штп Балтачтан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан авыл пунктларына китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (2020 елның 20 маендагы 182 номерлы, 2020 елның 16 октябрендәге 304 номерлы үзгәрешләр белән)

Балтач муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләрендә яшәүчеләрне сәүдә хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында, ««Юридик затларга, шәхси эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар җитештерүчеләргә, эшләр, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр бирүне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы бюджетыннан беренче чиратта кирәкле товарларны штп Балтачтан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан авыл пунктларына китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә (2020 елның 20 маендагы 182 номерлы, 2020 елның 16 октябрендәге 304 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктының 5 абзацында «(беренчел документацияне беркетеп)» сүзтезмәсен төшереп калдырырга.

2. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы бюджетыннан беренче чиратта кирәкле товарларны штп Балтачтан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан авыл пунктларына китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларынын чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 20 маендагы 182 номерлы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Преамбулада ««Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) шәхси эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар җитештерүчеләргә, эшләр, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары» сүзтезмәсен ««Юридик затларга, шәхси эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар җитештерүчеләргә, эшләр, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр бирүне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары» сүзтезмәсенә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.С. Галимуллин